| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КРЫНДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КЫРЫНДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2018 Кырынды авылы № 13

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге уставы белән, 2018 елның 1 октябрендәге 43-1 номерлы җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Кырынды авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И. Закиров

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Кырынды авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.12.2018 №13
белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү I группа инвалидлар, торып укучы студентлардан тыш, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан 30.03.2019 вакытка кадәр, аларның җирле референдумда катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә башкарыла.

3. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгару, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

4. Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5.Гражданнарның үзара салымнан алынган акчалары Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегенең лицевой (шэхси)счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты аша күчерү хокукына ия булган оешма аша күчерү яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Кырынды авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.12.2018 №13 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № ______

Түләүченең Ф.И.Ә.и. ____________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________
Нигезләмә ____________________________________________________
Сезгә _______________________ көнгә кадәрге вакыт эчендә _________________
_____________________________чараны гамәлгә ашыру буенча _____ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы БИК ______________________________________
Сч. № __________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ________________________________________
ИНН ___________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________
Түләүнең билгеләнеше ____________________________________________________

Җитәкче ___________________ _____________________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**

___________________________________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне _________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и. ____________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________

Кабул ителде «__ __» ___________ 20__ ел. _____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм _______________ җирлеге башкарма комитетында кала.*